ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ютазинская, д.14А,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ютазы урамы, 14А йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 2-44-12, факс:2-44-13, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№9

КАРАР
«21» май 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын һәм схемасын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы 89-ФЗ санлы Федераль законның 13.4 маддәсе, 2018 елның 31 августындагы «Каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1039 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- №1 кушымтага ярашлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын.

- 2 кушымтага ярашлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары схемасын.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 25 июлендәге «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын һәм схемасын раслау турында»гы 23/1 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге электрон адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте

һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.


4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.


5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина

2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары схемасы





Поиск по координатам
Широта 54.68642173
Долгота 53.43153368
Поиск по адресу
Байряжинское сельское поселение
Ютазинский район
Татарстан
Приволжский федеральный округ
Скопировать ссылку
Маршрут на автомобиле
54.68642 с.ш. 53.43153 в.д.
16К-1715
Помощь бездомным животным